| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10.03.2021** **№ 13**

Зур Полянка ав.

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 02 мартындагы 11 номерлы Зур Полянка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының 2020 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе Беркетмәсен игътибарга алып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы

**Зур Полянка авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Зур Полянка авыл җирлеге Советының 2021 елның 02 мартындагы 11 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәнең 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«3.3.8. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында белешмәләр (ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелә), авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә);».

2. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **М.Р.Афанасьева**